ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
СПАССКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
СПАС
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**

№ 893

**КАРАР**

«16» 12 2019 ел

Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы
Башкарма комитетының 2015 елның 26 гыйнварындагы
37 номерлы карары белән расланган « 2015-2020 елларга
Татарстан Республикасы Спас муниципаль районында
дәүләт милли сәясәтен гамәлгә ашыру»
программасына үзгәрешләр кертү турында

«2014 - 2020 елларга Татарстан Республикасында дәүләт милли сәясәте концепциясе турында» Татарстан Республикасы Президентының 2013 елның 26 июлендәге ПУ-695 номерлы Указы нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2014 - 2020 елларга Татарстан Республикасында дәүләт милли сәясәтен гамәлгә ашыру» дәүләт программасын раслау турында» 2013 елның 18 декабрендәге № 1006 Карарын үтәү, Татарстан Республикасының Спас муниципаль районында дәүләт милли сәясәтен гамәлгә ашыру, Спас муниципаль районы территориясендә яшәүче халыклар вәкилләренең цивилизацияле үсеше, этникара һәм конфессияара тынычлыкны һәм татулыкны саклау максатларында, Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы Башкарма комитетының 2015 елның 26 гыйнварындагы 37 номерлы карары белән расланган 2015-2020 елларга Татарстан Республикасы Спас муниципаль районында дәүләт милли сәясәтен гамәлгә ашыру» программасына үзгәрешләр кертергә.

2. Әлеге карарны Спас муниципаль районының рәсми сайтында бастырырга http:/ www.spasskiy.tatarstan.ru.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары Е.В. Савиновка йөкләргә.

Спас муниципаль районының
Башкарма комитеты җитәкчесе В.А. Осокин

Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы
башкарма комитеты карарына кушымта
«16» 12 2019ел № 893

**«2015-2020 ЕЛЛАРГА СПАС МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНДА ДӘҮЛӘТ МИЛЛИ СӘЯСӘТЕН ГАМӘЛГӘ АШЫРУ» ПРОГРАММАСЫ ЧАРАЛАРЫ ИСЕМЛЕГЕ**

| Чара | Срок | | Көтелә торган турыдан-туры нәтиҗә | Башкаручылар |
|---|---|---|---|---|
| | гамәлгә ашыру башы | гамәлгә ашыру тәмамлану | | |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
| **Мәсьәлә исеме: 1. Татарстан Республикасында дәүләт милли сәясәте өлкәсендә муниципаль органнарның граждан җәмгыяте институтлары белән үзара хезмәттәшлеген камилләштерү** | | | | |
| 1.1. Татарстан Республикасы Спас муниципаль районында Дәүләт милли сәясәте концепциясен гамәлгә ашыру программасын эшләү һәм кабул итү. | 2015 ел | 2020 ел | күрсәтелгән программаны Спас муниципаль районында гамәлгә ашыру | ТР Спас муниципаль районы башкарма комитеты, мәдәният бүлеге |
| 1.2. Гражданнар өчен конфликтлы хәлләр турында мәгълүмат кабул итү буенча ышаныч тартмалары булдыру һәм аларның эшчәнлеген оештыру. | 2015 ел | 2020 ел | Спас муниципаль районында конфликтларны институтлаштыру | Болгар шәһәр башкарма комитеты, авыл җирлекләре башлыклары. |
| 1.3Милләтара һәм конфессияара мөнәсәбәтләр өлкәсендәге эшчәнлекне гамәлгә ашыручы Спас муниципаль районында социаль юнәлешле коммерциягә карамаган оешмаларга ярдәм оештыру. | 2015 ел | Даими 2020 ел | Спас муниципаль районының милләтара һәм конфессияара мөнәсәбәтләр өлкәсендә социаль юнәлешле коммерциягә карамаган проектларны гамәлгә ашыру | ТР Спас муниципаль районы башкарма комитеты |
| 1.4. Конссиональ мөнәсәбәтләр буенча ведомствоара район комиссиясе эшчәнлеге. | 2015 ел | Даими рәвештә Комиссиянең эш планы | Муниципаль хакимият органнарының традицион конфессияләр белән үзара хезмәттәшлеген ныгыту | ТР Спас муниципаль районы башкарма комитеты |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | | буенча комиссия утырышы | | |
| 1.5. Спас муниципаль районында туризм үсеше | 2015 ел | 2020 ел | Спас муниципаль районында туристлык инфраструктурасын камилләштерү | Спас муниципаль районы башкарма комитеты, мәдәният бүлеге, Болгар дәүләт тарих-архитектура музей-тыюлыгы |
| 1.6. Милләтара конфликтларны кисәтү буенча мәдәният, мәгариф хезмәткәрләренең киңәшмәләрен үткәрү. | 2015 ел | 2020 ел | Милләтара хезмәттәшлек өлкәсендә социаль киеренкелекне киметү | Мәдәният бүлеге, район мәгариф бүлеге |
| **Мәсьәлә исеме: 2. Татарстан Республикасында яшәүче халыкларның этномәдәни үсеше өчен шартлар тудыру** | | | | |
| 2.1. Исламның «Изге Болгар жиены» кабул итүенә бер ел тулуны бәйрәм итү уңаеннан чараны әзерләүдә һәм уздыруда катнашу. | 2015 ел | май-июнь айлары 2020 ел | Татар халкының мәдәни-тарихи хәтерен саклау. | ТР Спас муниципаль районы башкарма комитеты, мәдәният бүлеге, Болгар дәүләт тарих-архитектура музей-тыюлыгы |
| 2.2. «Нәүрүз», «Май чабу» бәйрәмнәрен үткәрү | 2015 ел | Март ае 2020ел | Халыкларның мәдәни-тарихи социализациясе | Мәдәният бүлеге |
| 2.3. "Татар моңы"халыкара яшь башкаручылар телевизион конкурсында катнашу. | 2015 ел | Ноябрь 2020 ел | Яшьләрне мәдәни-тарихи социализацияләү | Мәдәният бүлеге |
| 2.4. «Борынгы болгарларның бөек җирендә балалар»музыкаль марафоны. | 2015 ел | Май 2020 ел | Яшьләрне мәдәни-тарихи социализацияләү | Мәдәният бүлеге, ДШИ |
| 2.5. "Түгәрәк уен" Бөтенроссия татар фольклоры фестивалендә катнашу") | 2015 ел | Август 2020 ел | Халыкны мәдәни-тарихи социальләштерү | Мәдәният бүлеге |
| 2.6. Спас муниципаль районында яшәүче халыкларның бәйрәмнәрен үткәрү: "Сабантуй", «Иван Купала», районда яшәүче халыклар фестивале һәм башкалар. | 2015 ел | Июнь-август 2020 ел | Халыкны мәдәни-тарихи социальләштерү | Мәдәният бүлеге |
| 2.7. «Созвездие-Йолдызлык»республика конкурсында катнашу. | 2015 ел | Май 2020 ел | Яшьләрне мәдәни-тарихи социализацияләү | ОДМС, Мәдәният бүлеге, район мәгариф бүлеге |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 2.8. Бөтенроссия Спас ярминкәсендә катнашу. | 2015 ел | Август 2020 ел | Халыкны мәдәни-тарихи социальләштерү | Мәдәният бүлеге, Болгар дәүләт тарих-архитектура музей-тыюлыгы |
| 2.9. Спас муниципаль районында туган тел көнен бәйрәм итүгә багышланган чаралар комплексын оештыру һәм уздыру | 2015 ел | Февраль 2020 ел | Туган телне саклау һәм өйрәнү. | Мәдәният бүлеге, район мәгариф бүлеге |
| 2.10. Спас муниципаль районында яшәүче халыкларның милли спорт төрләре буенча ел саен үткәрелә торган спартакиадасын, традицион уеннарны оештыру һәм уздыру. | 2015 ел | Февраль-май 2020ел | Милли спорт төрләрен саклау һәм үстерү | ОДМС |
| 2.11.Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы территориясендә туган як тарихын өйрәнү, Татар теле һәм әдәбиятын саклау максатыннан оештырылган «Туган тел» Республика яшьләр профильле сменасын үткәрү.. | 2015 ел | Июнь-август 2020ел | Туган телне саклау һәм өйрәнү. | район мәгариф бүлеге |
| 2.12.Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы территориясендә «Сәләт-Болгар»республика яшьләр сменасын уздыру. | 2015 ел | Июнь-август 2020 ел | Халыкны мәдәни-тарихи социальләштерү | ОДМС |
| 2.13. Республика һәм Россия халык иҗаты конкурсларында һәм фестивальләрендә катнашу. | 2015 ел | Гыйнварь, август 2020 ел | Халыкны мәдәни-тарихи социальләштерү | Мәдәният бүлеге, район мәгариф бүлеге |
| 2.14. Татарстан Республикасы көненә, Шәһәр көненә багышланган чаралар үткәрү. | 2015 ел | Август 2020 ел | Халыкны мәдәни-тарихи социальләштерү | Горисполком, Мәдәният бүлеге |
| **Мәсьәлә исеме: 3. Татарстан Республикасында дәүләт милли сәясәтен гамәлгә ашыруны фәнни-белем һәм мәгълүмати тәэмин итү** | | | | |
| 3.1. Спас муниципаль районында милләтара һәм конфессияара мөнәсәбәтләрнең торышына мониторинг үткәрү | 2015 ел | Декабрь 2020 ел | Спас муниципаль районында милләтара һәм конфессияара сәясәт алып бару | Болгар шәһәр башкарма комитеты, авыл җирлекләре башлыклары.. |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 3.2. Спас муниципаль районында яшәүче халыкларның берләшүе факторы булган тарихи даталарны Спас муниципаль районы массакүләм мәгълүмат чараларында киң яктыртуны тәэмин итү | 2015 ел | Ноябрь 2020 ел | Халыкны мәдәни-тарихи социальләштерү | Газета редакциясе «Новая жизнь – Яна тормыш» |
| 3.3. Конфессияләр вәкилләре катнашында «Без бердәм» түгәрәк өстәлен уздыру. | 2015 ел | Август 2020 ел | Спас муниципаль районында милләтара һәм конфессияара сәясәт алып бару | Мәдәният бүлеге, район мәгариф бүлеге |
| 3.4. Спас муниципаль районының массакүләм мәгълүмат чараларында этникара һәм конфессияара мөнәсәбәтләр мәсьәләләрен иң яхшы яктыртуга район журналистлар конкурсы оештыру | 2015 ел | Октябрь 2020 ел | Спас муниципаль районында милләтара һәм конфессияара сәясәт алып бару | район мәгариф бүлеге, Газета редакциясе «Новая жизнь – Яна тормыш» |